КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 декабрь г.Казань № 1072

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 февраль, 87 нче; 2016 ел, 14 июль, 479 нчы; 2017 ел, 29 ноябрь, 923 нче; 2018 ел, 31 июль, 622 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә, 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Планлы тикшерү үткәргәндә әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдалану барлык юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү үткәргәндә гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү үткәргәндә файдаланыла торган тикшерү кәгазьләре (контроль сораулар исемлекләре) гомергә, гражданнар сәламәтлегенә зыян, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян салу куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүне булдырмау күзлегеннән чыгып, аларны саклау аеруча әһәмиятле

булган юридик затка һәм шәхси эшмәкәргә куелган мәҗбүри таләпләргә кагыла торган мәсьәләләрне үз эченә ала.

Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә (контроль сораулар исемлекләренә) кертелгән мәсьәләләр исемлеге белән чикләнә.

Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына беркетелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин